# КАРАР

## Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**24 ноябрь 2021 ел** **№ 01**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нырты авылында өлешчә Совет, өлешчә Бакча, өлешчә Мәктәп урамы юлларын ремонтлау (вак таш, ком, торбалар, асфальт сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза уздыру);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Нырты авылы юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырткычларын алыштыру һәм карап тоту (яктырткычлар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (артезиан скважинасы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су саклау каланчасы идарә щитын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, су торбасына кран-задвижка сатып алу һәм урнаштыру);
- Нырты авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү);
- Православие дине зираты коймасын буяу өчен материаллар сатып алыну (смета төзү, материал сатып алу, алып кайту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 401 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 244 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 244 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «««Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Армиясе сафларында ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Нырты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Нырты авылында өлешчә Совет, өлешчә Бакча, өлешчә Мәктәп урамы юлларын ремонтлау (вак таш, ком, торбалар, асфальт сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, экспертиза уздыру);
- Җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү);
- Нырты авылы юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырткычларын алыштыру һәм карап тоту (яктырткычлар сатып алу һәм килешү буенча эшләр өчен түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- Су белән тәэмин итү ситсемасын төзекләндерү (артезиан скважинасы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су саклау каланчасы идарә щитын ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү, материал сатып алу, су торбасына кран-задвижка сатып алу һәм урнаштыру);
- Нырты авылы территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета төзү);
- Православие дине зираты коймасын буяу өчен материаллар сатып алыну (смета төзү, материал сатып алу, алып кайту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү;
- Видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (смета төзү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т. А. Котдусов

НЫРТИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ • ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НЫРТЫ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ОГРН 1061675011243
ИНН 1623008592